ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2017 Казан ш. № 10-127/кс

Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга 2018 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 10-127/кс карарына кушымта

## Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга 2018 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Җылысаклагыч компоненты, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Куәт ставкасы, мең сум/ Гкал/сәг бер айга | Җылылык энергиясе ставкасы, сум/Гкал |
| | Казан шәһәре | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1.1 | Кулланучылар | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 23,50 | 1422,87 | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 24,44 | 1482,63 | - | - |
| 1.1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 27,73 | 1678,99 | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 28,84 | 1749,50 | - | - |
| 1.2. | Яр Чаллы шәһәре | | | | | |
| 1.2.1 | Кулланучылар | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 28,94 | 1288,56 | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 30,10 | 1341,66 | - | - |
| 1.2.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 34,15 | 1520,50 | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 35,52 | 1583,16 | - | - |

<*> «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен җылысаклагыч компонентлары исәбенә кабул ителә торган җылысаклагычка тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылысаклагычка Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2015 № 5-35/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы

тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү турында» 01.12.2017 № 5-51/тэ карары белән билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге